РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ **КАРАР**

Кукмара ш.

22 марта 2019 года № 207

Аерым җирлек өчен әһәмиятле булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларында гомуми кулланылыштагы парковкалар оештыру турында

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында юл хәрәкәтен оештыру, парковкалар булдыру, аның эшчәнлеген тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясенең Градотөзелеш кодексы, 2003 елның 6 октябрендә чыккан “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131 Федераль закон, 2007 елның 8 ноябрендә чыккан “Россия Федерациясендә автомобиль юллары, юл эшчәнлеге һәм аерым закончалык актларына үзгәрешләр керту турында”гы №257 Федераль закон, 1995 елның 10 декабрендә чыккан “Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы турында”гы №196 Федераль законнарына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставына нигезләнеп, Кукмара муниципаль район Советы карар чыгарды:

1.Расларга:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районындагы аерым урын өчен әһәмиятле булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларында түләүле һәм түләүсез парковкалар (парковка урыннары) булдыру тәртибен (кушымта №1)

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми кулланылыштагы һәм гомуми кулланылышта булмаган парковкаларның реестры Нигезләмәсен (кушымта №2)

2.Әлеге карар рәсми басмада басылып чыгарга тиеш.

Район башлыгы С.Д. Димитриев

Кукмара муниципаль районы

Советы карарына (№207

2019нчы елның 22 мартыннан)

Кушымта №1

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирлегенә керүче автомобиль юлларында транспорт чараларын кую урыннарын булдыру һәм аларны куллану, шул исәптән түләүле нигездә дә,

Тәртибе.

1. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирлегенә керүче автомобиль юлларында транспорт чараларын кую урыннарын булдыру һәм аларны куллану, шул исәптән түләүле нигездә дә, Тәртибе (алга таба Тәртибе) Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы, 1995 елның 10 декабрендәге №196-ФЗ "Юл йөрү куркынычсызлыгы турында", 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру турындагы гомуми принциплар", 2007 елның 8 ноябрендәге №257 -ФЗ "Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юллар эшчәнлеге, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" гы Федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына, Татарстан Республикасы законнарына, актларына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставына туры китереп һәм нигезләнеп эшләнде.

2. Тәртип Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирлегенә керүче автомобиль юлларында транспорт чараларын кую урыннарын булдыру һәм аларны куллану, шул исәптән түләүле нигездә дә, процедурасын эченә ала.

3. Тәртиптә кулланылучы төп терминнар, төшенчәләр 2007 елның 8 ноябрендәге №257 –ФЗ "Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юллар эшчәнлеге, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында"гы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексындагы мәгънәдә кулланылалар.

Тәртип максатларында шулай ук тубәндәге төшенчәләр кулланыла:

- барлык кеше дә файдалана алырлык гомуми кулланырга мөмкин булган автомобиль кую урыннары – парковка;

- түләүле автомобиль кую урыннары – гомуми файдалану өчен түләүле нигездә;

- түләүсез автомобиль кую урыннары – транспорт чарасын вакытлыча куеп тору очен җиһазландырылган, әмма транспорт хуҗаларыннан түләү алынмый.

- парковкадан файдаланучы (парковка урыныннан) - парковкада (парковка урынында) транспорт чарасын урнаштырган зат;

- парковка операторы (парковка урынындагы оператор) - Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тарафыннан парковканы (парковка урынын) оештыру һәм эксплуатацияләү өчен вәкаләтле Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль учреждениесе яисә оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә, конкурс нигезендә сайлап алынган шәхси эшмәкәр;

- түләү җиһазы (паркомат) - парковкадан (парковка урыныннан) файдаланган өчен түләү алуның техник чарасы), ул 2003 елның 22 маенда кабул ителгән 54-ФЗ номерлы “Парковкадан (парковка урыныннан) файдаланган өчен түләү алуның техник чарасы, түләү карталарыннан файдаланып акча исәп-хисапларын һәм (яки) исәп-хисапларны тормышка ашыру турында"гы, 2009 елның 3 июнендә кабул ителгән 103-ФЗ номерлы "Түләү агентлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган физик затларның түләүләрен кабул итү эшчәнлеге турында"гы Федераль закон таләпләренәҗавап бирергә тиеш.

2. Парковкалар (парковка урыннары) төзүнең максатлары һәм тәртибе.

1. Парковкалар (парковка урыннары) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының үткәрү сәләтен арттыру һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру максатларында оештырыла.

2. Гомуми файдалану территорияләрендә планлаштыру структурасы элементлары чикләрендә, күпфатирлы йортлар салынган гомуми файдаланудагы парковкалар төзү турындагы карар Башкарма комитет тарафыннан территорияне планлаштыру буенча расланган документация нигезендә, шулай ук гомуми файдаланудагы шундый территорияләргә якын урнашкан күпфатирлы йортлардагы бүлмә милекчеләренең фикерләрен исәпкә алып кабул ителә. Күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләренең фикерләрен ачыклау һәм исәпкә алу, шулай ук планлаштыру структурасы элементының чикләрен билгеләү муниципаль норматив хокукый актларда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Күпфатирлы йорттагы милекчеләренең гомуми милкенә караган җир кишәрлеге чикләрендә гомуми файдаланудагы парковкалар төзү торак законнары һәм җир законнары нигезендә кабул ителә.

3. Парковканы (парковка урынын) төзү белән кызыксынган зат Башкарма комитетка парковканы (парковка урынын) төзү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

Гаризага парковка (парковка урыннары) булдыруның максатка ярашлы булуын нигезләү, түләүле нигездә парковкадан (парковка урыныннан) файдалану яки түләү алынмый торган Тәкъдим һәм парковканы (парковка урыны) урнаштыру проекты теркәлә. Парковканы (парковка урыннарын) урнаштыру проектын карап тотарга тиеш:

1) парковка (парковка урынын) булдырыласы җирне, аның чикләрен һәм төгәл сыйдырышлылыгын күрсәткән схемасын;

2) парковкалар (парковка урынын) оештыру җире билгеләнгән ТР Кукмара муниципаль районы буенча гомуми файдалану әһәмиятендәге автомобиль юлының түбәндәге өлешләре күрсәтелгән фрагмент планы:

-парковка (парковка урынының) урнашкан җире(адресы);

-парковка(парковка урынының) мәйданы;

-автомобиль юлы өчен бүлеп бирелгән полосаларның чикләре;

-кызыл сызыкларның чикләре(әгәр алар әлеге территориядә булса)

4. Парковка (парковка урынын) булдыру өчен кирәкле материаллары белән парковка (парковка урынын) урнаштыру турындагы башкарма хакимиятенә килеп кергән проект 3 эш көне эчендә(килеп кергән көненнән алып) җибәрелә:

а) килеп кергән көненнән алып 10 эш көне эчендә әлеге материаллар парковка (парковка урынын) җәелдерү проектының гамәлдәге законга туры килүен ачыклау, нәтиҗә чыгару өчен башкарма хакимиятенең инфраструктура үстерү булегенә;

б) килешенү өчен:

-ТР Кукмара муниципаль районының гомуми файдалану әһәмиятендәге автомобиль юлын баланста тотучыга;

-Кукмара районы буенча Россия эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ бүлегенә;

-инженерлык челтәре һәм элемтә бүлеге хуҗасына(-ларына)

5. Парковка (парковка урынын) булдыру турындагы проектны килеп кергән вакытыннан алып 10 календарь көне эчендә башкарма хакимияте структура бүлекләре хәл итәләр.

6. Башкарма хакимияте килеп кергән килешенүләр һәм нәтиҗә нигезендә парковка (парковка урынын) булдыру турындагы гаризаны карый һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

-парковка (парковка урынын) булдыру һәм аны түләүсез куллану;

--парковка (парковка урынын) булдыру һәм аны түләүле куллану;

--парковка (парковка урынын) булдыруны кире кагу

7. Парковка (парковка урынын) булдыруны кире кагуның нигезе булып түбәндәгеләр тора:

-гамәлдәге тәртип матдәсенең 2 кисәгендә каралган кирәкле документның(-ларның) булмавы;

-парковка (парковка урынын) булдыру проектының гамәлдәге тәртип матдәсенең 2 кисәгендә каралган таләпләренә туры килмәве;

-парковка (парковка урынын) булдыру проекты килешенүендә тискәре нәтиҗәнең һәм дәлилләнгән кире кагылуның булуы.

8. Парковка (парковка урынын) булдыру турында башкарма хакимияте карар чыгара, ул түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

-парковка (парковка урынының) урнашу җире(адресы);

-парковка (парковка урынының) мәйданы, чикләре;

-парковкада машина урыннарының саны;

-парковка (парковка урынының) операторынын атамасы. Әгәр дә ул ТР Кумара муниципаль районының муниципаль учреждениясе булса, яисә парковка (парковка урынының) операторын сайлау конкурсын үткәрү срогы;

-парковка (парковка урынын) булдыру буенча чаралар.

9. Парковка (парковка урынын) булдыру турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткән зат, нәтиҗә чыгарылып, 3 эш көне вакыт эчендә язма рәвештә таныштырыла.

10. Парковка (парковка урыны) операторын сайлау конкурсын үткәрү тәртибе башкарма хакимияте тарафыннан билгеләнелә.

3. Парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдалану тәртибе.

1.Парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдалану түләү нигезендә яки түләүсез оештырыла.

2. Парковкалар белән файдаланучы парковка белән куллану турындагы кагыйдәләр, парковкалар белән түләүле рәвештә кулланган очракта түләү күләме, түләүләрне кертү тәртибе һәм ысуллары турында хәбәрдар булырга хокуклы. Парковкалар белән файдалану кагыйдәләре башкарма хакимияте хокукый актлары тарафыннан раслана.Башкарма хакимияте түләүле парковкалар булдыру һәм алардан файдалану турындагы карарны әзерләү хакында халыкка рәсми материалларны һәм хәбәрләрне, тиешле мәгълүматларны “Хезмәт даны”(“Трудовая слава”) газетасы битләрендә, шулай ук Кукмара муниципаль районы официаль сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында, түләүле парковкалардан файдалана башлауга кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, түбәндәге мәгълүматны урнаштырып, хәбәр итүне тормышка ашыра:

1) түләүле парковкалардан файдалану зарурлыгын нигезләүне, гомуми файдаланудагы парковкалардан файдаланган өчен түләү кертү ярдәмендә юл хәрәкәте өлкәсендәге хәл ителуе планлаштырыла торган төп проблемаларны;
2) түләүле парковкалардан файдалана башлау датасын;
3) муниципалитет территориясендә булдыру күз алдында тотылган түләүле парковкалар зоналарын;
4) түләүле парковкалардан файдалану тәртибен;
5) парковкалардан файдаланган өчен түләү күләмен һәм аны башкару тәртибен.

3. Парковкада (парковкалау урынында) парковка (парковка урыны) операторы тарафыннан түбәндәгеләрне үз эченә алган мәгълүмати щит эшләнә:

-парковка (парковка урынының) эшләү вакыты;

-парковкадан (парковка урыныннан) файдаланган өчен түләү күләме (әгәр парковка түләүле булса);

- автомобиль кую урыннары түләүле булган очракта бу урынны файдалану тәртибе һәм түләү чаралары;
- транспорт чарасын куеп тору урынының Интренет челтәрендәге сайты, атамасы, адресы, контакт телефоны;
- транспорт чарасын куеп тору урынынында автомат рәвештә фотога төшерү, видео яздыруга белешмә;
- транспорт чарасын куеп тору урынынныннан файдаланучылардан язмача дәгъва кабул итү урыннары хакында белешмә.

4. Транспорт чарасын куеп тору урыны өчен түләү паркомат дип аталган акча түләү җиһазы ярдәмендә башкарыла.

5. Транспорт чарасын куеп тору урынынннан файдаланучы автомобиль кую урынында буш урын булса, үзенең транспортын элеге урынга куя ала.

6. Транспорт чарасын куеп тору урынынннан файдаланучы түбәндәге таләпләрне төгәл үтәргә бурычлы:

1) Россия Федерациясенең Юл йөрү кагыйдәләрен һәм тәртибен төгәл үтәргә;
2) транспорт чарасын куеп тору урынында үз транспортын сызылган линия һәм юл билгеләренә нигезләнеп урнаштырырга;
3) транспорт чарасын куеп тору урынын купмы вакыт файдаланганына карап азкча түләргә;
4) акча түләгәннән соң 10 минут дәвамында урынны бушатырга.

7. Транспорт чарасын куеп тору урыны өчен җаваплы оператор түбәндәге таләпләрне үтәргә бурычлы:

1) кабул ителгән карар һәм Тәртипкә нигезләнеп транспорт чарасын кую урынындагы эшләрне оештыра;
2) транспорт чарасын куеп тору өчен кирәкле булган барлык җиһазларны, шул исәптән акча түләү өчен паркомат, информация элү щитларын, башка кирәкле техник әсбапларны урнаштыра, төзек булуларын тәэмин итә, саклый;
3) транспорт чарасын куеп тору урыны урнашкан территориянең чисталыгын, төзеклеген тәэмин итә;
4) транспорт чарасын куеп тору урынын файдаланучылардан үзвакытында түләүне контрольдә тота;

8. Транспорт чарасын куеп тору урыннарында автомобильләрне кертү, чыгару, анда тоту тәртибе Россия Федерациясенең Юл йөрү кагыйдәләренә нигезләнеп башкарыла.

9. Һәрбер транспорт чарасын куеп тору урынында 10%тан ким булмаган машина урыны (1 урыннан да ким булмаска тиеш)

инвалидлар өчен махсус автотранспорт чараларын кую өчен билгеләнгән парковканың (парковка урынының) гомуми саныннан чыгып билгеләнә. Күрсәтелгән машина кую урыннарына башка транспорт чаралары куелырга тиеш түгел.

10. Түләүле парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдаланган өчен түләү бәясен Башкарма комитет үзләре тарафыннан расланган “Түләүле парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдаланган өчен исәп-хисап Методикасы” нигезендә билгели.

Парковкаларны (парковка урыннарын) түләүле нигездә кулланудан кергән керемнәр, гамәлдәге законны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетына кертелә.

11. Түләүле парковкадан (парковка урыныннан) файдаланучылардан парковкадан (парковка урыныннан) файдаланган өчен түләүләрдән башка түләүләрне алу рөхсәт ителми.

12. Түләүле парковкадан (парковка урыныннан) файдаланган түбәндәге кулланучылар парковка (парковка урыны) өчен түләүдән азат ителәләр:

- инвалидларның махсус автотранспорт чарасы;

-Россия Федерациясе Президентының 2012нче елның 19 маенда чыккан 635нче номерлы "Транспорт чараларына куела торган махсус яктылык һәм тавыш сигналларын бирү өчен җайланмаларны куллануны тәртипкә салу турында”гы боерыгы нигезендә махсус яктылык һәм тавыш бирү чаралары белән җиһазландырылган транспорт чаралары.

13. Килеп туган бәхәсләрне җайга салу максатларында, парковкалар (парковка урыннары) операторы тарафыннан парковкадан (парковка урыныннан) файдалану фактларын теркәү автомат рәвештә фотога төшерү һәм видеоязмалар ярдәмендә гамәлгә ашырыла, ул исә парковкада (парковка урынында) урнаштырылган транспорт чараларының дәүләт теркәү номерлары турында белешмәләрне теркәү, җыю, саклау һәм куллануны үз эченә ала.

14. Тәртип статьясының 13нче өлешендә каралган мәгълүматларны парковка (парковка урыны) операторы тарафыннан саклау һәм куллану барышында, парковка (парковка урыны) операторы әлеге мәгълүматны өченче заттан файдалану мөмкинлеген саклау һәм яклау буенча гамәлдәге законда каралган барлык чараларны да кабул итә.

4. Парковкалардан файдалануны туктату тәртибе

1. Парковкадан (парковка урыннарыннан) файдалануны туктату турындагы карар Башкарма комитет тарафыннан әлеге Тәртип статьясының 2нче өлешендә каралган нигезне раслау көненнән соң 10 эш көне эчендә карар чыгару юлы белән кабул ителә.

2. Парковкадан (парковка урыннарыннан) файдалануны туктату турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

- парковка (парковка урыны) урнашкан Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлы участогында юлда йөрү хәрәкәтен оештыру схемасы үзгәрешләре

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлының парковканы урнаштыру белән бәйле үткәрү мөмкинлеген киметү

- тиешле территориядә шәһәр төзелеше хәлен үзгәртү

- парковкадан (парковка урыныннан) алга таба файдалану мөмкинлеген бирми торган гамәлдәге законны бозу факты ачыкланган очракта

3. Башкарма комитетның парковкадан (парковка урыныннан) файдалануны туктату турындагы карары үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

- парковканы(парковка урынын) урнаштыруурыны (адресы)

- парковкадан(парковка урыныннан) файдаланунытуктатунигезләмәсе

- парковкадан(парковка урыныннан) файдаланунытуктатуның вакыты

4. Парковкадан (парковка урыныннан) файдалануны туктату турындагы карар күчермәсе карар кабул ителгән көннән алып 3 эш көне эчендә парковка операторына җибәрелә.

Кушымта №2

Кукмарамуниципаль районы

Советыныңнда №207 карарына

22 март, 2019 ел

Татарстан Республикасы Кукмарамуниципаль районы территориясендә урнашкангомумифайдаланудагыпарковкалар (парковка урыннары) һәм аерымкулланылыштагыпарковкалар реестры турында нигезләмә

1.Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы парковкалар (парковка урыннары) һәм аерым кулланылыштагы парковкалар реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибен билгели.

"Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында "2007 елның 8 ноябрендәге" 257-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында да тәртиптә кулланыла торган төп терминнар һәм төшенчәләр шул ук мәгънәдә кулланыла

Әлеге положениедә йомышсыз файдалану парковкалары дигәндә чикләнгән затлар даирәсенең транспорт чаралары куелырга тиешле территория кузда тотыла.

2. Кукмара муниципаль районының Башкарма комитеты Реестрны формалаштыра һәм алып бара һәм реестрга парковкалар турында мәгълүмат кертүдә, реестрдагы мәгълүматларны актуальләштерүдә җаваплы.

3.Реестр электрон формада алып барыла һәм анда реестр язмалары яисә күрсәтелгән язмаларга үзгәрешләр кертелә ала. Реестр язмасының формасы Кукмара муниципаль районының Башкарма комитеты боерыгы белән килешенә.

4.Реестр мәгълүмати ресурс булып тора, анда муниципаль районы территориясендә урнашкан һәм, милек формасы һәм билгеләнеше нинди булуга карамастан, барлык йомышсыз файдалану парковкалары һәм гомуми кулланылыштагы парковкалар (парковка урыннары) хакында белешмә тупланган.

5. Йомышсыз файдалану парковкалары һәм гомуми кулланылыштагы парковкалар реестрына түбәндәге мәгълүматлар кертелә:

1)парковканың адресы (урнашкан урыны);

2)парковканың төре, тибы, билгеләнеше;

3)транспорт чарасын парковкада урнаштыру шартлары (түләүле, бушка);

4)парковканың эш режимы;

5) милек формасы һәм парковканың милекчесе турында мәгълүмат;

6)парковканың операторы турында мәгълүмат;

7)парковкадагы парковка урыннарының гомуми саны;

8) льготалы категорияле кулланучылар өчен билгеләнгән парковка урыннарының саны.

6.Реестр алып бару өчен беркетелгән җаваплы хезмәткәр Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы нигезендә билгеләнә.

7.Реестрда булган мәгълүмат ай саен яңартыла.

8.Реестр эше муниципаль берәмлекнең башка мәгълүмати системалары һәм ресурслары белән бергәлекне булдыручы бердәм оештыру, методологик, программа-техник принципларга туры китереп алып барыла.

Кукмара муниципаль районының Башкарма комитеты Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча ЮХИДИ бүлегенә һәм шулай ук вәкил оешмаларына Положениенең 5нче пунктында күрсәтелгәнреестр белешмәләренә керү мөмкинлеген булдыра.

9.Реестрның резерв күчермәсе мәгълүматны саклау максатларында ярты елга бер тапкырдан да ким итмичә булдырыла.

10. Реестрдагы мәгълүматларны рөхсәтсез керүдән саклау махсус мәгълүмат саклау чаралары тарафыннан гамәлгә ашырыла

11.Парковкалар реестры мәгълүматлары Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарының вәкаләтле органнары тарафыннан статистика мәгълүматларын төзү, бердәм парковка пространствосы өлкәсендә чараларны күздә тоткан муниципаль программаларны эшләү, Кукмара муниципаль районы территориясендә парковкалар урнаштыру һәм генераль планнарны һәм җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрен төзү кагыйдәләрен актуальләштерү буенча тәкъдимнәр керту максатларында кулланыла.